ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЛЫН-БАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

2025 ел, 5 декабрь №7

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге башлыгының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2025 елның 25 ноябрендәге апрелендәге 994 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 гыйнварындагы 102 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлегенең башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «21091» санын «23201» санына алмаштырырга;

2.2 пунктта «15389» санын «16928» санына алмаштырырга.

2.Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Болын-Балыкчы авыл җирлеге башлыгы,
Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы рәисе Л.М.Гайнетдинов